ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.12.2024**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 4765**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 05 сентябрендәге 2703 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен Зеленодольск районы җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.[1] статьясы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 05 сентябрендәге 2703 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен Зеленодольск районы җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктның җиденче абзацында «тапшыралар» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә;

1.2. 4 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«-Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның регламентын билгели»;

1.3. 5 пунктның «б» пунктчасының алтынчы абзацында «тапшыралар» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә;

1.4. 5 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«-бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү;

- Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның регламентын билгеләү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру».

2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин